# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында**

**1 статья.** «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәне кертергә:

1. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Вөждан иреге, дин тоту иреге турында һәм дини берләшмәләр турында Татарстан Республикасы законнары**

Вөждан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нормаларыннан, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган бүтән норматив хокукый актлардан гыйбарәт.».

2. 5 статьяда:

10 пунктны төшереп калдырырга;

11 һәм 12 пунктларны 10 һәм 11 пунктлар дип санарга.

3. 9 статьяда:

1 пунктта «унсигез яшенә җиткән кимендә ун кешедән торган» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дини төркем төзеп, аны киләчәктә дини оешмага үзгәртү нияте булган гражданнар аның төзелүе һәм эшли башлавы турында җирле администрациягә хәбәр итәләр.».

4. 10 статьяда:

5 пунктны төшереп калдырырга;

6, 7, 8 пунктларны 5, 6, 7 пунктлар дип санарга.

132

5. 13 статьяда:

1 пунктта «законда» сүзен «Россия Федерациясе законнарында» дигән сүзләргә алмаштырырга;

2 пунктның алтынчы абзацында «уставның нотариуста расланган күчермәсен һәм үзәкләштерелгән әлеге дини оешманы теркәү турындагы таныклыкны тапшырган килеш;» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үзәкләштерелгән дини оешма тарафыннан яисә үзәкләштерелгән дини оешма биргән раслама нигезендә төзелүче дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы гариза әлеге статьяда каралган барлык документлар тапшырылган көннән соң бер ай эчендә карала. Теркәүче орган дәүләт дин белеме экспертизасын үткәрү өчен документлар карауны кайбер очракларда алты айга кадәр озайтырга мөмкин. Дәүләт дин белеме экспертизасын үткәрү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

7 һәм 12 пунктларны төшереп калдырырга;

8-11 пунктларны 7-10 пунктлар дип санарга.

6. 14 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацын төшереп калдырырга.

7. 15 статьяның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Хөкүмәте» дигән сүзләрне «Россия Федерациясе Хөкүмәте» дигән сүзләргә алмаштырырга.

8. 16 статьяда:

2 пунктның өченче һәм унҗүртенче абзацларын төшереп калдырырга;

16 статьяның 4 пунктында «дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

9. 18 статьяның 6 пунктында «Татарстан Республикасы Хөкүмәте» дигән сүзләрне «Россия Федерациясе Хөкүмәте» дигән сүзләргә алмаштырырга.

10. 28 статьяның 2 пунктында «һәм дин эшләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

11. 30 статьяда:

4 пунктка түбәндәге редакциядә яңа икенче һәм өченче абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә кимендә унбиш ел гамәлдә булуын раслаучы документы булмаган дини оешмалар күрсәтелгән унбиш ел тулганга кадәр ел саен яңадан теркәлү шарты белән юридик зат хокукларыннан файдаланалар.

Күрсәтелгән дини оешмалар әлеге чорда 4 статьяның 4 пунктында, 6 статьяның 4, 5, 6, 8 пунктларында, 15 статьяның 6 пунктында, 19 статьяның 4 пунктында, 21 статьяның 1 һәм 2 пунктларында, 22 статьяның 2 пунктында (белем бирү учреждениеләренә һәм массакүләм мәгълүмат

чараларына карата кулланылучы) һәм 23 статьяның 2 пунктында каралган хокуклардан файдаланмыйлар.»

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 сентябре
№ 1077